зәгыйфьләнер, мәчетләрдә намаз укучылар азаер, кешеләр арасында өлфәт һәм мәхәббәт бетәр, кешеләрнең дәрәҗәсе акча белән генә үлчәнер. Тәкәбберлек артар, дуслык һәм туганлык азаер. Бу хәлләрнең икесе дә аянычтыр. Шуның өчен мөселман дөнья тормышын да дөрес итеп алып барырга, ахирәтне дә онытмаска тиеш. Чын мөселман - дөнья вә ахирәт эшләрен тигез алып барыр. Аллаһы Тәгалә дөньяны да, ахирәтне дә иманлы коллары өчен бар иткән. Дөньяда бәхетле булыр өчен ахирәтне онытмыйча, тырышлык белән яшәргә кирәк. Чөнки дөнья тормышы фанидыр, ул бик тиз үтеп китәчәк. Ахирәт тормышы гына мәңгедер.

Кешеләрне күп вакыт ялкаулык чолгап ала. Башкарылачак эшләр кала, кылыначак гыйбадәтләр дә казага калдырыла. Фәкать ясалачак эшләр иртә соң башкарылачактыр. Ул вакытта ни өчен кешеләр эшләрен соңгы минутка калдыралар яисә һич җитештерә алмаслар? Чөнки ялкаулык дигән хасталыкка юлыгырлар. Әйе, ялкаулык — чирдер, һәм бу чирне йоктырмауның иң гарантияле юлы - ялкауланмау.

Пәйгамбәребез ялкаулыкны бер дә хуш һәм хуп күрми һәм дәвамлы болай дога кыла: *“Аллаһым, ялкаулык һәм мескен хәлдән сиңа сыенамын”.* Пәйгамбәребез буш вакытның шайтанны чакыруын хәтерләткән. Кул кушырып утыручы кешеләрнең бары тик куллары буш кала. Зиһеннәре, йөрәкләре, күңелләре исә һәрвакыт хәрәкәттә. Әгәр дә бер кеше бер эш белән мәшгуль булып, зиһенен, күңелен ул эшкә бирми икән, шайтан аларны мәшгуль итүнең юлларын табар. Үзенә ияртү өчен әлеге юлларны кешегә матур итеп күрсәтер. Шуның өчен бер дә буш торырга ярамый.

Коръән-и Кәримдә бер эштән икенчесенә күчеп, зиһен, йөрәк һәм күңелне файдалы эшләр белән мәшгуль итү зарурлыгы хәтерләтелә. Кеше ял иткәндә дә тик тормый. Кешенең табигатендә, үзендә һәрвакыт мәшгуль булу, эшләү, җитештерү бар. Аллаһының әмере дә боларны җиренә җиткерүдер. Аллаһы Үзенең буш вакыты юк. Яралткан кешедән дә моны көтә. Җир йөзендә эшләп, аны үзе өчен коруын тели. Алма агачына алма үстерүне өйрәткән Аллаһы кешенең иң гүзәл алмаларны җитештерүе өчен эшләвен тели. Җиргә һәртөрле үсемлекне чыгару сәләтен биргән Аллаһы Тәгалә кешедән дә җирне эшләтүен көтә. Иң мөһиме: кешенең кеше белән мәшгуль булуын, ягъни кешенең кешене үстерүен, өйрәтүен, җитештерүен тели. Бу да, һичшиксез, тырышлык белән генә чынга аша. Аллаһы эшләүчеләрне һәм кешелек өчен файдасы булганнарны сөя. Безне дә эш итүче һәм кешелеккә файдалы булганнардан әйләсен.

**Рәмзия ӘГӘ.**

*(“Иман” газетасыннан)*

# Әхлак кешене бизи

## Атаның баласы алдындагы хокуклары

Бала ата-анасына карата яхшы мөнәсәбәттә булырга тиеш. Бала йомшак мөгамәләле, тырыш, бигрәк тә анасы белән мәрхәмәтле булырга өйрәнсен. Ә инде әни кешенең мәрхәмәтле һәм яхшы күңелле булуы шарт. Гөнаһ булмаган һәр очракта бала әти-әнисен тыңларга тиеш. Ул әти-әнисенә карата дустанә, йомшак күңелле, аларның дусларына карата итагатьле (алар исән чакта да, әти-әнисе вафатыннан соң да) булуы мөһим. Бала ата-анасын догадан калдырмаска, туганнарына барып, хәлләрен белешеп торырга тиеш. Үзенең олы һәм кече туганнарына карата да итагатьле һәм мәрхәмәтле булу әхлаклылык санала.

## Баланың ата-ана алдындагы хакы

Ата-ана бала туганчы ук аның кирәк нәрсәләрен әзерләргә, кем туса да - малаймы, кызмы - сөенергә, кыз туган очракта борчылмаска тиеш. Бала тугач, әти кеше баланың уң колагына - азан, сулына икамәт әйтә. Матур, мәгънәле исем сайлап, 7 көн тулгач исем кушылырга тиешле. Элек малай туса - ике сарык, кыз туса - бер сарык корбан чалганнар. Әти кеше баланың теш казнасына җимеш йә башка татлы нәрсә белән массаж ясый. Ата-ана какмый-сукмый тәрбияли, балага 7 яшь тулгач, укырга-язарга өйрәтә, таһарәт алырга, догалар укырга күнектерә. Тыңламаса - мәҗбүр итә. 9 яшь тулгач, йокы бүлмәсеннән баланы ир туганнарыннан аерырга кирәк. Ата-ана баланы үзләреннән күңеле кайтырлык итеп рәнҗетергә тиеш түгел.

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*

*БӘЕТ*

**Похвистнево районының Гали авылында яшәгән яраткан әткәебез Халит Харис улы СӘЙФЕТДИНОВның вафат булуына 24 февральдә 40 көн була. Мин барлык якыннары-туганнары исеменнән аңа багышлап бәет яздым.**

## Әткәебезгә

*Сиңа багышлап шигырь яздым,*
*Яраткан әткәебез.*
*Син булмагач, ятимләнеп*
*Калды безнең йортыбыз.*

*Селкенмичә ятасың син,*
*Күзләреңне йомгансың.*
*Бу авыр көн безнең сине*
*Азакы күрүебез.*

*Кечкенә генә сакалыңны*
*Тотып-тотып карадым.*



№ 9 (1188), 23 февраль 2013 ел
Бердәмлек 5

күбесендә юк, чөнки ул мөселманлык төсе дип санала. Мөселманнарда исә яшел төс диннең яңалыгы, чисталыгы белән тасвирлана, кешене наданлыктан яктылыкка чыгаручы буларак кабул ителә.

Көнбатыш илләрендә кара төс төн, үлем, үкенү, бушлык символы булып санала. Ләкин исламда аның бу расланышын тапмыйбыз. Киресенчә, Аллаһы йорты – Кәгъбә кара япма белән капланган, ул алтын белән чигеп бизәлгән. Габбасилар династиясе кара байраклар йөрткән, Пәйгамбәребез кара чалма кигән. Исламда кара төснең тискәре мәгънәсе яки тәэсире булмауны раслаучы бик күп мисаллар китерергә мөмкин.

Ак төс барлык төсләрне тигез рәвештә эченә алган. Бу - сафлык, гадилек, сабырлык, тынычлык төсе. Шунысын да билгелисе килә: Көнбатышта үлем, кайгы кара төс белән бәйле, Көнчыгыш илләрендә исә үлем ак төс белән ассоциацияләнә. Мәетне ак кәфенгә төреп күмәләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә ак төсне яраткан. *«Ак киемнәр киегез, тереләр дә акны кисен, мәетләрне дә акка төрегез. Чөнки ак кием – иң яхшы кием»,* – дигән.

Кызыл төс зур әһәмияткә ия түгел. Ул кайбер мөселман илләренең әләмнәрендә кулланыла. Моңардан башка Кызыл ярымай сурәте Көнбатыштагы Кызыл хачка тиң рәвештә карала. Беренче тапкыр бу символ Госманлы империясе белән Рәсәй арасындагы конфликт вакытында (1877-1878 елларда) күзәтелгән. Һәм ул хәзер 33 дәүләт тарафыннан файдаланыла. Аны ислам дәүләтләре флагларында да күрергә мөмкин.

Зәңгәр яки күк Якын Көнчыгышта саклану төсе булып тора. Бик күп танылган мәчетләр шушы төскә буялган. Аларның берсе – Истанбулдагы Күк мәчет.

Сары төскә килгәндә, Пәйгамбәребез сакалын сарыга буйый торган булган, дип язылган кайбер хәдисләрдә. Бу максатта ул сары агачны һәм зәгъфран үләнен кулланган. Фикердәшләренең чәчләрен кынага буявын хуплаган. Хәтта бервакыт Мәдинәдә өлкән яшьтәгеләргә мөрәҗәгать итеп: *«Әй, ансарлар! Чәчләрегезне кызыл һәм сары төсләргә буягыз...»* – дигән. Берничә хәдистә исә кара төстән баш тартырга тәкъдим ителә. Шулай ук кызыл кием кию дә тыелганнардан санала. Ләкин галимнәр арасында бу турыда бердәм фикер юк. Ибн Хаҗр «Фәтхүл-Бари» әсәрендә бу мәсьәләгә карата сигез фикер урнаштырган. Әммә алар арасыннан өчесен аерырга мөмкин:

- кияргә киңәш ителми (мәкруһ);
- башка төсләр белән бергә булганда гына мөмкин;
- кызылны кияргә мөмкин.

Шәригатьтә бары бер генә тыелган төс турында беләм. Киемдә тыелган төс – ул әфлисун сары, кызыл сары (оранжевый), һәм бу тыю бары ирләргә кагыла.

Ислам кешенең барлык аспектларын эченә алган: рухый, мораль, физик, эмоциональ, интеллектуаль, социаль. Бу динне кабул иткән һәркем күпкә яхшыра. Аның тормышы башка төс ала. Аллаһы үзе исламны «Сибгатулла» (Алла төсе) дип атады. Ягъни дин кешенең тормышына, сыйфатына яңа төс кертә. Әгәр ислам бары ритуал яки кодекс кына булса, «сибга» (төс) дип аталмас иде, бу инде тормышның барлык өлешләренә таралган образ.

Исламның үзенчәлекле темпераменты аркасында Аллаһы дингә карата төсләр образын кулланган да. «Коръән хөкемнәре Аллаһы динедер! Аллаһы диненнән күркәмрәк дин булырмы, һәм без Аңа гына итагать итәбез», - диелә «әл-Бәкара» сүрәсенең 138 нче аятендә.

Ислам – ул бөек шатлык, җанга тынычлык, бәхет. Кешегә шатлыкны кием аша күрсәтү дә хас. Моны шулай эшләргә дә кирәк. «Әл-Әгъраф» сүрәсенең 31 нче аятендә болай диелә: *«Ий, Адәм балалары! һәр сәҗдә кыла торган урында зиннәтле киемнәрегезне алып киегез, ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз, тәхкыйк Аллаһы исраф итүчеләрне сөйми».* Ягъни халык арасына яки мәчеткә барганда кеше аеруча яхшы киенергә тиеш, дип куша Аллаһы Тәгалә. Киемнең төсе исә зур роль уйный: ул мөселманлыкны, шатлыкны, пакьлекне чагылдырырга тиеш. Безнең да тормышыбыз «ислам төсе» белән буянсын, Изге Китабыбызда язылганча тормыш итик, башкаларга үрнәк булыйк. Әмин.

**Дамир хәзрәт ХӨСӘЕНОВ.**

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*

# Һәр милләтнең нигезен тәшкил итүче гаилә җаваплылыгы

Башка җан ияләре белән чагыштырылган чакта кешенең ни чаклы үзгә һәм өстен үзенчәлекләргә ия булуы анык рәвештә күренә. Чыннан да, Бөек Аллаһы кешене һәр җәһәттән иң гүзәл рәвештә яралткан. Башка яралтылган барлыкпардан аермалы буларак өстен сәләтләр бирелгән инсан - уйлаучы, сөйләүче, яралтылуының, барлыкка китерелүенең хикмәтен эзләүче һәм өйләнешеп оя коручы, гаилә учагын төзүче бердәнбер җан иясе. Кешенең башка җанлылардан аермалы буларак өйләнгәнлекне даими тәртипкә салуы - хосусый буларак тикшерелүе зарур тема вәзгыятендә.

Иң элек шуны әйтеп узарга кирәк: кешенең өйләнешеп гаилә төзү үзенчәлеге - аның яралтылу табигатенә бәйле вәзгыять. Кешенең бар булу шартлары - бер гаилә эчендә яшәвен зарур кыла. Бөек Аллаһы Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Һаваның араларына рухи